**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕРӘШ-ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XLVII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 1**

Керәш-Шуран авылы 06 май, 2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына һәм законнарга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларга һәм законнарга үзгәрешләр кертү буенча эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнар һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү» турындагы нигезләмәне раслау хакында.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына:

үз норматив иҗади эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

әлеге Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы затлар итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы**
**Керэш-Шуран авыл җирлеге башлыгы** **Р.Г.Сафиуллин**

«Расланган»

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Крэш-Шуран авыл җирлеге
Советының
2019 ел, 06 май, 1 нче санлы
карары

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына һәм законнарга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингы (алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) үз вәкаләтләре чикләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлеген, мәгълүмат кабул итүне (бастыруны) тәэмин итү өчен җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча, муниципаль актларны үзгәртү яки көчен югалткан дип тануны (гамәлдән чыгару) күздә тота.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3. Җирле үзидарә органнары мониторинг үткәргәндә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы аппаратының юридик хезмәте (юридик бүлеге) һәм муниципаль берәмлекнең башка җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итәләр.

4. Җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып:

федераль һәм республика законнарына туры китерү максатларында муниципаль актларны кабул итү, үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану ихтыяҗларын ачыклау;

муниципаль актларда коллизияләрне, каршылыкларны, бушлыкларны (кимчелек, пробел), хокукый җайга салуда кабатлауларны бетерү;

җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

муниципаль актларда коррупциячел факторларны ачыклау;

муниципаль актларның яисә аларның аерым нигезләмәләренең (нормаларның) гамәлдә файдаланылмаган (актуальлеген югалткан) яисә кулланылмаган нигезләмәләрен ачыклау;

хокукый куллану нәтиҗәлелеген арттыру; муниципаль актларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген киметүче факторларны ачыклау;

муниципаль актларның үтәлешен тәэмин итүдә җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан контрольне гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

канунчылык (нормалар чыгару) буенча эш барышын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү тора.

6. Мониторинг үз эченә үзгәрешләрне җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләүне ала:

федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка закон актларын;

Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, федераль дәрәҗәдәге законга кагылышлы башка норматив хокукый актларны;

Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларын;

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы норматив хокукый актларын;

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Уставы, муниципаль актларын.

7. Мониторинг үткәрүнең нигезләре булып:

федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертү;

хокукый җайга салуның билгеле бер өлкәсендә муниципаль актларны куллануны анализлау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

муниципаль актларның кимчелекләре яки аларны камилләштерү турында массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүматы;

гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмаларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында мөрәҗәгатьләре, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелгән муниципаль актларга карата үткәрелгән хокукый экспертиза бәяләмәсе;

билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затлар тарафыннан муниципаль актларга карата коррупциягә каршы әзерләнгән экспертиза бәяләмәләре;

җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган конференцияләр, семинарлар, гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышуларның һәм башка чараларның йомгаклау документларын үз эченә алган мөрәҗәгатьләр тора.

## II. Мониторинг үткәрү тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары, аларның компетенциясе мәсьәләләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән берлектә мониторинг үткәрәләр.

Мониторинг үткәрү максатларында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат соратып алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсе өйрәнелергә, башка эш формалары кулланылырга мөмкин.

9. Мониторинг:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актлар;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау эшләре буенча суд актлары (суд практикасы);

прокурор актлары анализы аша башкарыла.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру, жирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелгән норма булдыру эше нәтиҗәләрен теркәү максатларында муниципаль берәмлекнең жирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын булдыру һәм алып бару тәртибе турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә башкарыла торган муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла.

11. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимизацияләү өчен мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары кулланылуны (аларның операторлары белән килешүләр төзүгә бәйле, күрсәтелгән мөмкинлекләр булганда):

«Гарант» мәгълүмат системасында контрольгә куелган закон һәм башка норматив хокукый актларга үзгәрешләр турында мәгълүмат керү;

«Гарант» мәгълүмат системасын хокукый жайга салуның тиешле өлкәләре буенча яңалыклар тасмалары мәгълүматы керү;

«Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Региональ законнар аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан муниципаль актларның законнарга туры килмәве турында мәгълүмат керүне тәэмин итү.

Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатларында башка мәгълүмат системалары сервислары да файдаланыла ала.

12. Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны) тәэмин итү, әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән бергә үз көчләрен югалтуын (гамәлдән чыгаруны) тану өчен мониторингны гамәлгә ашырганда муниципаль актларны куллану практикасы турында мәгълүмат түбәндәге критерийлар буенча гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау;

муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару) зарурлыгын билгеләгән зуррак юридик көчкә ия норматив хокукый актларның булуы;

муниципаль акт чыгарганда жирле үзидарә органы компетенциясе чикләрен саклау;

муниципаль актта коррупциячел факторлар булу;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуда тулылык;

коллизия хокук нормалары;

юридик-техник характердагы хаталар булу;

кулланганда муниципаль акт нигезләмәләренең мәгънәсен бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда хокуксыз яисә нигезсез карарлар, гамәлләр кылу (гамәл кылмау);

норматив хокукый актларны куллану тәҗрибәсе булу;

норматив хокукый актларны куллануның бердәм тәҗрибәсе булмавы;

муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризалар (саны) һәм эчтәлеге;

муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турындагы закон көченә кергән суд актлары һәм аларны кабул итү нигезләре.

13. Мониторинг нәтиҗәләре буенча федераль һәм республика законнарында муниципаль актларның үзгәрүенә китерә торган үзгәрешләр ачыкланган очракта, жирле үзидарә органнары тарафыннан:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актның үз көчен югалтуын тану турында, яңа муниципаль акт кабул итү турында тиешле муниципаль актлар проектлары эшләнә;

муниципаль актларны күбрәк юридик көчкә ия булган актлар белән тәңгәлләштерүгә юнәлдерелгән башка чаралар күрелә.

14. Муниципаль актларны үзгәртү ихтыяҗын тудыручы федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг федераль яки республика акты басылып чыкканнан соң 30 көн эчендә үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шулай ук прокуратура мәгълүматы торса, «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль законда билгеләнгән вакыт аралыгында карала торган прокурор актларыннан тыш, мониторинг мөрәҗәгать кергән көннән алып, 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Әлеге очракларда мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүче затка хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларының ерак киләчәктә (перспективада) үз көченә керә торган үзгәрешләре ачыкланган очракта, жирле үзидарә органнарының норматив эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Муниципаль акт проектын эшләү һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль актны кабул итү, әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, федераль һәм (яисә) республика законнарының тиешле акты үзгәртелгәннән соң ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар жирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында хисаптан соң килүче айның 5 көненнән (числосыннан) дә соңга калмыйча, мониторинг нәтиҗәләре турында хисап тота.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүмат;

мониторингны үткәрүчеләр турында мәгълүмат;

мониторингны үткәрү вакыты турында мәгълүмат;

хокукый җайга салу предметының кыскача характеристикасы, мониторинг үткәрү өчен нигезне алырга тиеш.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә:

хокукый җайга салуда ачыкланган проблемалар турында мәгълүмат;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа муниципаль актларны кабул итү, юкка чыгару зарурлыгы турында тәкъдимнәр;

тиешле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән, мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәрне алырга мөмкин.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча кабат кабул ителгән муниципаль актлар законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм вакыт аралыгында Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрелә.

Регистрга кертү өчен мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган, әлеге регистрда булмаган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча нормалар булдыру барышын (процессын) камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг үткәрү һәм хокукый-иҗади эшчәнлек өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру, шулай ук муниципаль актларны җирле үзидарә органнары карамагына караган тиешле хокукый җайга салу өлкәсендә федераль һәм республика законнарына туры китерү (яраклаштыру) өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар)
җавап бирә.

20. Тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китерүче мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлләр кылган (гамәлләр кылмау) өчен законнар нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җавап бирә.